РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
КОРСАБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Корсабаш, ул. Школьная, д. 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУРСАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.04.2026

КАРАР
№14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында керемнәр турында белешмәләр урнаштыру мәсьәләләрен җайга сала торган 22.12.2012 №33, 22.08.2017 №16 карарларының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 ел, №505-ФЗ Федераль законга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Курсабаш авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Үз кечен югалткан дип таныйрга:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 22.12.2012 елның №33 «Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару ечен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары;

-Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 22.08.2017 елның №16 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирү Тәртибен раслау турында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Курсабаш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче» карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба

муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/korsabash адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Курсабаш авыл
җирлеге Башлыгы

А.Р. Гыймадиев